# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Мишә торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 7 декабре** **Олы Мишә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Олы Мишә торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Мишә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 700 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Мишә авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-су башнясы өчен тирән насос алу;

- Тукай урамы буенча юлларга вак ташҗәелгән юлларга ремонт ясау (таш ташу вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Ленин һәм Мәктәп урамнары арасындагы җәяүлеләр юлына вак таш җәю (таш ташу, таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Школьная урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту;

- Школьная урамында балалар уен мәйданчыгы төзелеше;

- зиратта җирләү инвентаре саклау өчен материал сатып алу һәм будканы ремонтлау;

- урам яктырткычлары, энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- янгын сүндерү автоцистернасын ремонтлау;

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру?»

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 251 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 167 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 167 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Мишә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Мишә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 700 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Мишә авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-су башнясы өчен тирән насос алу;

- Тукай урамы буенча юлларга вак ташҗәелгән юлларга ремонт ясау (таш ташу вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Ленин һәм Мәктәп урамнары арасындагы җәяүлеләр юлына вак таш җәю (таш ташу, таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Школьная урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту;

- Школьная урамында балалар уен мәйданчыгы төзелеше;

- зиратта җирләү инвентаре саклау өчен материал сатып алу һәм будканы ремонтлау;

- урам яктырткычлары, энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- янгын сүндерү автоцистернасын ремонтлау;

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

- кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Олы Мишә авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мишә авыл җирлеге Башлыгы: Г. Ә. Маннапов